**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Салтык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

20 нче ноябрь 2020 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 нчы елның 20 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә, түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясе Олы Салтык авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Олы Салтык авылы чишмәсе юлына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Олы Салтык авылы скважинасының санитар-яклау зонасин коймалау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 246 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 135 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 135 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенә керүче Олы Салтык авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясе Олы Салтык авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге

эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:
- Олы Салтык авылы чишмәсе юлына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Олы Салтык авылы скважинасының санитар-яклау зонасын коймалау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)" соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясе Олы Салтык авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:
- Олы Салтык авылы чишмәсе юлына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Олы Салтык авылы скважинасының санитар-яклау зонасын коймалау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт,
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге
башлыгы: Р.М.Вафин